Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 59/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә:

Татар Ялтаны авылы, Хәмзин ур., 50 йорт (административ бина);

Татар Ялтаны авылы, Кооператив ур., 9 йорт (Мәдәният йорты бинасы)

Изгар ав., Школьная ур., 13/1 (2 нче админстратив бина)


3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Гарифуллин

Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
59/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Хәмзин округы | Подгорная, Хәмзин, Подлесная (тулысынча), Завод урамы 1-11 йортлар (барлык йортлар) | 57 |
| 2 | 2 нче Клуб округы | Завод урамы 12-22 йортлар (барлык йортлар), Кооператив, Союз урамы (тулысынча) | 58 |
| 3 | 3 нче Садовый округы | Садовая урамы (тулысынча) | 59 |
| 4 | 4 нче Молодежный округы | Пролетарская урамы, Молодежная урамы (тулысынча),1-9 йортлар (барлык йортлар) | 57 |
| 5 | 5 нче Заречный округы | Заречная урамы 10-46 йортлар (барлык йортлар), Спорт урамы (тулысынча) | 54 |
| 6 | 6 нчы Школьный округы | Садовая, Лесная, Школьная (тулысынча),1-5 йортлар (барлык йортлар) | 51 |
| 7 | 7 нче Полевой округы | Полевая урамы 6-31 йортлар (барлык йортлар), Молодежная урамы (тулысынча), Рус Ялтаны авылы | 50 |


Рус. Елтан
округ № 7
округ № 6
округ № 4
округ 3
округ 2
округ № 5
округ 1
Тат.Елтань